Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылындагы
гражданнар җыены

# КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 24 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- бульдозер эшләре, авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларын җыю территориясен обваловка һәм трамбовкалау, килешүләр буенча эшләр өчен түләү;
- агымдагы, капиталь ремонт, авыл эчендәге чокырлы юлларны ремонтлау, килешүләр буенча түләү

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 221 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 122 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«**РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 122 катнашучысы тавыш бирде;

**«**КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- бульдозер эшләре, авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларын җыю территориясен обваловка һәм трамбовкалау, килешүләр буенча эшләр өчен түләү;

- агымдагы, капиталь ремонт, авыл эчендәге чокырлы юлларны ремонтлау, килешүләр буенча түләү.

3. Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- бульдозер эшләре, авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларын җыю территориясен обваловка һәм трамбовкалау, килешүләр буенча эшләр өчен түләү;

- агымдагы, капиталь ремонт, авыл эчендәге чокырлы юлларны ремонтлау, килешүләр буенча түләү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татар Талкышы авыл җирлеге
башлыгы ________________ М.М.Вәлиев